
ISSN 0868-4545



Салават күпере



Саба безгә юл саба

Сәлам, дуслар! Бүген без күңелле сәяхәткә чыгабыз. Саба якларында яшәүче малайлар һәм кызлар үзләренә кунакка чакырды. Алар «Салават күпере»н укучы яшьтиләрен үз мәктәпләре, шөгыльләре, иҗат эшләре белән таныштырырга тели. Ямьле Мишә буйларын, Саба урманнарын, бу якның якты йөзле кешеләрен барып күрик әле! Форсаттан файдаланып, Премьер-министрыбыз Рөстәм абыегыз Миңнехановны да 50 яшьлек юбилее белән котлыйбыз! Ул да шушы төбәк мәктәпләрендә белем алган, канат ныгыткан Саба егете бит! Хәерле сәгатьтә хәерле сәфәргә!



Зиннур ХӨСНИЯР

Әни теләкләре

Рөстәм МИҢНЕХАНОВКА

Әни сыер сава, сөте куе,
Бүлеп куя балаларына.
Әниләрчә һаман кайгырта ул:
– Сөтем булсын кайтуларына.

Әйе, Әни кеше, малайларың –
Синнән өзелеп төшкән егетләр.
Шулай булгач, сиңа охшаганнар,
Җилдәй җитез, бөркет кебекләр!

Ирен чите белән елмая ул:
— Рәхәт сагынып көтүләре.
Кемгә охшаганмы? – Мәгълүм инде:
Әтиләре бит, әтиләре.

Әтиләре булды тынгысыз җан –
Күңлендә һаман урман шавы иде.
Һәр агачы аның килүләрен
Әллә кайдан танып алыр иде.

Ир-егетнең бәхте үз кулында,
Уе булсын Иле турында.
Тынгысызлык, мәңге тиктормас җан –
Тумыштан ук минем улымда.

Без очырдык кыю лачын итеп,
Өч тарафка тормыш юлыннан.
Хезмәт сөйгән ирне Иле мактар –
Бөек эшләр килер кулыннан!..

© "Салават күпере", 2007 ел

Бабам истәлеге

Бөртекләп чәчтең орлыкны,
Нәни агач шытсын, дип...
Үсентеләр үсеп җиткәч,
Болынга утырттың син.

Кырлар кибә, күләгә юк,
Юл буйлары ташландык...
Данлы эшләрең бу җирдә
Үсентедән башланды.

Шаулап үсә яшел урман,
Көннән көн ул ишәя.
Бал тамып торгач чәчәкләр:
«Мине ал!» – дип баш ия.

Уңган булдың, тырыш идең,
Күңелең – иркен ялан.
Юмарт белем орлыкларын
Безгә калдырдың, бабам!

Нияз МИҢНЕХАНОВ,
Лесхоз мәктәбе укучысы.



Рөстәм Миңнеханов авылдашлары — «Йолдыз» ансамбле (җитәкчесе Илназ Фазылҗанов) биючеләре арасында.





Саба районы, Лесхоз мәктәбе укучылары иҗаты.

Безнең Саба

Безнең Саба районы
Кояштай балкып тора.
Безнең Саба районы
Ямьле биналар кора.

Безнең Саба бик матур –
Ерактан балкып тора.
Безнең Саба бик ямьле –
Һәркемне тартып тора.

Матур бул син һәрвакыт,
Утларың янып торсын,
Кешеләрне һәрчак шулай
Үзеңә дәшеп тор син!

Гүзәл ШӘКҮРОВА.


Минем әти

Минем әтием бик эшчән.
Уңган балта остасы.
Һәр эшкә дә өлгер ул –
«Алтын кул»лы, кыскасы!

Әти ясаган урындык,
Шкаф, тартма, өстәлләр
Бардыр һәркемнең өендә,
Тимәсен генә күзләр.

Әти безне дә өйрәтә
Үз эшенең серенә.
Әти кебек булам, диеп,
Үсәм мин дә бүгеннән!

Булат СӘХӘПОВ, 9 яшь.



Альфред ШӘФЫЙКОВ, 9 яшь.



Рафил ӘХТӘМҖАНОВ, 10 яшь.



Елизавета НИКОЛАЕВА, 9 яшь.



Алсу АРСЛАНОВА, 11 яшь.

И әбием, әбием!

И әбием, әбием,
Беркайчан да авырма,
Гел елмаеп, көлеп тор.
Янында кем булганын
Син һәрвакыт белеп тор!
Оныгың үсеп җитәр,
Шәп табиб булып китәр.
Күп калмады бит инде –
Мин үскәнне көт инде!

Сөмбел САФИУЛЛИНА,
11 яшь.

Шарик

Бар минем маэмаем –
Исеме аның Шарик.
Яратам мин дустымны,
Яратам аны мин бик.
Миннән конфет сорый ул,
Койрыгын селки-селки.
«Шаригым, алтыным», – дим,
Башыннан сыйпый-сыйпый.
Этем мине яратканын
Күзләреннән күрәм мин.
Миңа да ул бик якын шул –
Этем моны белә бик!

Рафил ӘХТӘМҖАНОВ,
10 яшь.



Мин шәкертемнән канәгать

Чит җирләрдә озак йөргәч, авыл балаларын төсмерләп кенә таный идем. 6 «а» сыйныфына килеп керүгә рәхәт булып китте. Чөнки иң алгы партада үзебезнең күрше Нургали абый малае Рөстәм утыра. Мин аларга немес теленнән кердем. Үзем химик булсам да, башка фәннәрне дә укытырга туры килде.

Рөстәм малай чагында кечкенә гәүдәле булса да, әкәмәт көчле иде. Тик көче белән масаймады. Спорт ярата иде, гомумән, Рәфкать, Рөстәм, Рәис Миңнехановлар спорт белән дус булдылар, хәтта салкын кыш көннәрендә дә калын пәлтә кимәделәр, өсләрендә йон күлмәк һәм пинжәк иде. Соңрак Саба мәктәбенә дә алар чаңгы белән йөрделәр.

Рөстәм күп сөйләшергә яратмады, бик тәртипле иде. Кечкенәдән үк куйган максатына таба баручы җитди кеше булды. Белемгә омтылды. Шуңа күрә ул, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап эшли башлагач, икътисадчы һөнәрен дә үзләштерде.

Зур дәрәҗәләргә ирешсә дә, һаман шул ук гади һәм итәгатьле Рөстәм булып калды. Сабада эшләгән елларында көн саен Лесхозга кайтып йөри иде. Юлда кем очрый, һәммәсен дә машинасына утырта. Миңнехановларның барысы да шундый. Хәзер безнең авыл кешеләре иртән Сабага район башлыгы Рәис Миңнеханов машинасына утырып бара. Читенсенеп, кул күтәрми торсалар, үзе туктый.

Рөстәм техникага гашыйк булып үсте. Әтисе малае иде. Гел аның янында йөрде. Аның атаклы автоузышчы булып китүе очраклы түгел. Аның эшләрен газеталардан укып, телевизордан карап гел күзәтеп торам. Уңышларына сөенеп яшим. Шәкертемнән бик тә канәгать мин.




__Владимир АЛЕКСЕЕВ__ — Казан химия-технология институтын тәмамлагач, Урал якларында эшли. 1969 елда өлкән яшьтәге әнисен тәрбияләргә туган авылына кайта. Шуннан бирле мәктәптә химия укыта.

Урман мәктәбе

Лесхоз – урманчылар авылы. Шуңа күрә мондагы мәктәптә урман гыйлемен дә өйрәтәләр. Малайлар һәм кызлар һәр агачның, җәнлек-кошларның холкын белеп үсә.

Лесхоз балалары эшкә уңган, спорт белән дус, белемгә омтылучан. Фән олимпиадаларында, спорт ярышларында алар районда гел беренче.

Мәктәптә II сыйныфтан инглиз теле керә. Бүген бик тә кирәкле шушы телне Миләүшә апалары Хәбибуллина өйрәтә. «Рөстәм абый кебек зур кеше булгач, чит ил кунаклары белән тылмачсыз сөйләшербез!» – диләр укучылар.



Хәйләкәр аю

Татарстанда Лесхоз авылында бердәнбер «Урман музее» бар. Биредә эшләүче Рузия Газизуллина исемле мөлаем кыз балаларга Саба урман хуҗалыгының данлы тарихы, аның уңган кешеләре турында сөйли.

Музейда төрле кошлар, җәнлекләр дә күп. Менә бу аю бик хәйләкәр икән. Умартаның капкачын ачып, бал ашый да кире ябып куя ди. Кем урлашканын белмичә аптырашканнар. Аю үзенең хәйләсен музейга кунакка килгәч кенә сөйләп биргән.



Яшь урманчылар



Рузия Газизуллина



Атаклы урманчы Нургали Миңнехановның мотоциклы



Миләүшә Хәбибуллина



Афәрин, сабакташ!

Мәртен сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач, 9 нчы сыйныфка Саба урта мәктәбенә килдек. Дәресләр – икенче сменада, соң тәмамлана. Мәктәп интернатына урнаштык. Мин Лесхоз авылы егетләре белән бер бүлмәгә туры килдем, алар 9 Е сыйныфында белем алалар икән. Араларында Рөстәм исемлесе – аеруча кызыксынучан, күп белергә омтылучан, иптәшләрен үз артыннан әйдәүче, тиктормас яшүсмер – игътибарны җәлеп итте. Без аралашып киттек. Рөстәм төгәл фәннәрне аеруча яратып үзләштерә, дәресләргә ныклап әзерләнә, «дүрт»кә, «биш»кә генә укый. Үзара мөнәсәбәтләр кискенләшеп киткән чакларда Саба малайлары (район үзәге «җегетләре» бит!) белән дә араларны көйләү-җайлауны ул үз өстенә алды. Ул чакта ук аның уртак тел таба белү, башкаларны үз сүзенә ышандыру сәләте сизелеп тора иде. Рөстәмнең һәрчак үз фикере була, һәр вакыйга-күренешкә дөрес бәя бирә белә, яңалыкларны тиз эләктерә. Минем бераз гармун «шыңгырдатуым»ны белеп алгач, башкалар белән бергә аның да уйнарга өйрәнү дәрте кабынды. Вакыт булган саен, гармун тартабыз. Җиңел эш түгел бит, шактый акрын бара. Шулай да җаен таптык: көй тәртибенә карап, хромка телләренә саннар ябыштырдык. Озак маташкач, «Әпипә», «Пескәем» көйләре чыкты. Ләкин эш шуннан узмады, чөнки уку елы тәмамланып килә иде. Эш күбәйде, инде интернатта да көн саен кунмыйбыз – авылларга кайтып йөрибез.

Сабакташыбыз Рөстәм Миңнехановның зур кеше буласы мәктәп елларында ук сиземләнә иде. Хөкүмәт җитәкчесе дәрәҗәсенә ирешкән сабакташым, якташым белән ихластан горурланам мин. Һәм үз укучыларымда нәкъ менә анда булган асыл сыйфатларны тәрбияләргә тырышам.



Хәтмулла ВАККАЗОВ,
Кукмара районы, Байлангар урта мәктәбе директоры,
Татарстанның атказанган укытучысы.

Тел беренчеләр

Сабадагы 1 нче мәктәп – һәрьяктан да беренче. Ул Бөтенроссия бәйгесендә җиңү яулап, миллион сумлык бүләк алды.

Бик башлы балалар укый монда. Компьютерны биш бармаклары кебек beлэлэр. Интернетта чит илләрдәге яшьтәшләре белән дә аралашалар. Директорлары Ринат Хәбибуллин яңа җиһазларны алып кына тора.



Уйныйбыз да...



Ринат Хәбибуллин



... биибез дә!



Шамил Зиннуров

Футбол, хоккей уйнарга, чаңгыда узышырга ярата Саба малайлары. Районда җиңеп, республика ярышларына баралар.

Бу мәктәптә Әбрар Кәримуллин, Аллаһияр Вәлиуллин, Шәүкәт Биктимеров, Фасил Әхмәтов кебек күренекле шәхесләр укыган. Рәфкать, Рөстәм, Рәис Миңнехановлар да IX-X сыйныфларда шушында килеп белем алган. Саба районының баш мөгаллиме Шамил Зиннуров та биредә еш кунак.

Җәлләү

Делюс беренче сыйныфка укырга бара. Әтисе моңа һәр «5»легә бишәр сум акча вәгъдә итә уку елы башында. Башта көндәлектә «5»леләр берничәдән артмый. Тора-бара аларның саны күбәя башлагач, шып туктата әти кеше акча биреп бала бозуны. Зөфәр абый бер төшке аш вакытында Делюсның ничек укуы белән кызыксына:

– Улым, хәлләрең ничек соң? «5»леләр эләгәме?

– Гел «5»кә укыйм мин, бабай.

– Әтиең акча бирәме соң?

– Бирми. Туктатты.

– Акчасы юктыр аның, улым. Өй салырга җыенасыз бит. Кирпеч тә сатып алдыгыз...

– Акчасы бар аның, бабай, бар. Жәлли ул, жәлли!





Фәрит МУЛЛАХМӘТ рәсеме

Авыз белән ашау

Зөбәрҗәт ханым түтәлләрдән яңа гына өзелгән кыярларны юып, өйләренә алып кереп бара икән.

– Әби, әби, миңа да кыяр калдыр әле, – дигән оныгы Гадел, тимер-томыр белән майланып беткән кулларын сузып.

– Кулың пычрак бит! – дигән аңа Зөбәрҗәт ханым.

Гадел шунда ук:

– Мин кул белән түгел, авыз белән ашыйм бит! – дип әйтеп куйган ди.



Песи белән каз

Борын-борын заманда яшәгән ди песи белән каз. Алар бик тату һәм дус булган.

Каз елгада су коена, песи, өйдә калып, тычкан аулый икән. Менә беркөнне песи тычкан тоткан. Шул тоткан тычканы белән рәхәтләнеп уйнап утырганда каз кайтып кергән. Казның песигә бик ачуы килгән, чөнки кайтуына аңар ашарга бирүче булмаган.

Песи дустын җәлләгән һәм, өйгә кереп, үзенә бирелгән ипи белән майны алып чыгып биргән. Каз бик шатланган. Алар шулай дус, тату булып, бик озак гомер иткән ди. Әкият тә шунда беткән ди.

Фирүзә ЯРУЛЛИНА, 9 яшь.
Саба, Лесхоз.

Мактанчык әтәч

Яшәгән ди, булган ди бер әтәч. Ул бик мактана торган булган.

– Мин кояшны уятам! Кешеләрне уятам, – ди икән.

Аның мактануын тыңлап торган песи:

– Ә мин моңа бер тамчы да ышанмыйм! – дигән.

– Әйдә, алайса, тикшереп карыйк! – дигән Әтәч.

Болар урамга чыкканнар. Әтәч кычкырып җибәрүгә, кояш яктыртып, нурларын сипкән. Песи гаҗәпләнеп карап торган.

– Ура! Ура! Кояш чыкты! – дип кычкырып йөргән.

Әтәч ары киткән. Бу юлы ул чыпчыклар янына килгән. Әтәч аларга да шул ук сүзләрне әйткән. Чыпчыклар да башта ышанмаганнар. Әтәч кычкырып җибәргән, яңадан кояш чыккан. Чыпчыклар бик сөенгәннәр. Кояш тирәсендә оча башлаганнар.


Менә бервакыт бер хәл килеп чыккан: әтәч бүтән кычкыра алмаган. Тавышы беткән. «Гел мактанып йөргәч, шулай була инде!», – диешкәннәр чыпчыклар.

Күпмедер вакыттан соң әтәч терелгән. Ләкин аны барыбер «Мактанчык әтәч» дип йөргәннәр.

Ләйсән ИДРИСОВА.
Саба, Лесхоз.



Өлгер малай



Ничек өлгерәдер ул Миша Протасевич? Казандагы 324 нче балалар бакчасына йөри. Йөри әле ул тагын кечкенәдән зирәк балалар мәктәбенә, каратэга, театрга. Шулар өстенә китап укырга, компьютерда уйнарга, рәсем ясарга да өлгерә. «Барысын да яратам, шуңа күрә өлгерәм», – ди малай.

Иртән аны йокысыннан өйдәге Изик кушаматлы кенәри уята. Алар икесе дә аяз көннәрне яраталар. Миша канатлы дустын тәрәз төбенә алып килә һәм кояшка күз кысып тора, ә кенәри җырлый. Куанычлы мәшәкатьләре белән шатландырачак, байтак мизгелләре Миша Протасевичның кояшлы рәсемнәрендә чагылачак яңа көн башлана.





Кояшлы көн



Мин яраткан пингвиннар



Рифкать ХУҖИ

Телик компик Поттер һәм... Айрат

Айрат бик бирелеп мультфильм карап утыра иде. Шулчак әнисе эндәште:

– Улым, ашка бәрәңге чистартсаң иде?!

– Хәзер, әни, хәзер!

Мультфильм беткәч, Айрат кулына китап алды. Тылсымчы малай Гарри Поттер турында инде. Иң кызык җирендә генә тагын әнисенең тавышы ишетелде:

– Улым, эшкә соңга калам, чәй куярга тәмле чишмә суы беткән икән...

– Хәзер, әни, хәзер алып кайтам.

Китаптан соң компьютер уеннарына чират җитте. Бусы инде китаптан да мавыктыргычрак. Монда барысына да син хуҗа! Телисең икән – танк белән идарә итәсең, телисең – самолет штурвалын кулыңа аласың. Айрат компьютер дөньясына кереп батты. Әнисенең тавышы да хәзер бик ерактан гына килгән кебек иде:

– Улы-ы-м, дәресләреңне карарга вакы-ы-т...

– Ярар, әни, ярар!

Ялгызы гына бөтен бер «дошман» гаскәрен тар-мар итеп бетергәндә урамда кара төн җиткән иде инде. Күзләре кызарып авырта Айратның, әле тагын үтереп ашыйсы да килә. Тик аш бүлмәсе салкын, өстәл буш иде. Әнисе дә өйдә юк, әле дәресләр дә әзерләнмәгән. Математика китабын ачса – аның битендәге саннар сикерешеп бии үк башладылар...

Икенче көнне әнисе эштән кайткан төшкә Айрат күп итеп чишмә суы ташыды. Бәрәңгеләрне дә шул су белән юды. Өйне ялт иттерде. Күзеннән яшь агызып булса да, ашка суган да әрчеде әле. Шул вакытта математикадан алган «2»лесе турында да онытып торды хәтта.

Әнисе кайткач, икәүләшеп өстәл әзерләделәр. Һай ул көнне аш-чәйләрнең тәме... Телеңне йотарлык иде! Әнисе аны кочагына кысып башыннан сыйпады:

– Эшләп ашагач – шулай тәмле була инде ул, улым!

Рәссам Алла АЙСИНА



Сергей Малышев
шигырьләре



Светофорга карамыйча

Светофорга карамыйча,
Чыгабыз каршы якка.
Беркем кисәтү ясамый –
Борчылмый безнең хакта.
Уңга-сулга каранмыйча,
Ашыгабыз – чабабыз...
Без бит җир асты юлыннан
Каршы якка чыгабыз!

Рәссам Алла АЙСИНА

Тагансыз парк

Бу парк – шундый парк бу:
Карусель юк, таган юк...
Хәтта якшәмбе көнне дә
Монда бала-чага юк!

Монда оркестр уйнамый,
Концертлар да куймыйлар...
Бу паркта ял итмиләр
Һәм эшсез дә тормыйлар.

Бу парк – шундый парк бу:
Атынгыч-таганы юк...
Көндез мотор гүләвеннән
Һич тынып торганы юк!

Трамвайларны күргә,
Син аңладың, әлбәттә:
Эшләп кайткач, алар монда
Таңга кадәр ял итә!





Могҗиза

Мин бер тавык күрдем бүген –
Күрдем аны елгада:
Шундый оста йөзеп йөрде,
Тавык кына булса да.
Аннан... болытка ятып, ул
Йон-каурыен киптерде...
Аннан... бу сүзгә ышанган
Бер тилене мин күрдем!




Ямансу

Мультфильм да карап карыйм –
Һич кызык түгел.
Әни пешергән бәлеш тә
Тәмсез күк бүген.

Күңелле җыр сузган булам –
Җыр көйгә килми.
Кояш та бүген күңелсез –
Елмаймый, көлми.

Яфраклар да әллә ничек
Сөйләшә шунда:
Барысы да моңсу гына
Серләшә шунда...

...Кичә дустым җәй буена
Авылга китте.
Аның китүе мине бик
Ямансу итте.






Урысчадан Ләбиб ЛЕРОН тәрҗемәсе.





– Көн бик ямьле – кояшлы,
Кояшлы көн – бик яхшы...
Мин менә, яңгыр көтеп,
Ятамын зонтик тотып.

Әлки, Әхмәт.



– Иренмәдек, бакчабызга
Орлык сиптек бер табак.
Энем белән икәү бергә
Үстердек без зур кабак!

Саба, Югары Симет.





– Көтә-көтә арыдык,
Хәлләрем бетте инде:
Кәбестәләр арасыннан
Кайчан табарлар мине?!


Саба.



– Кыска булса да буем,
Бик кызык минем уем –
Исәп: абый җилкәсендә
Йөрергә көне буе!

Актаныш.

Чәчәкләрем-төсләрем



Төзеде Гүзәл СӘЕТОВА


Сканвордта кулланылган чәчәкләр: роза, лилия, астра, гвоздика, мимоза, кыңгырау, тузганак, умырзая, сирень, кактус, ромашка, ландыш, лалә, нәркис.

Бер борчак... ике борчак...

Балалар, сезнең борчак ашаганыгыз бармы? Ә борчак шытканын күргәнегез?.. Бәлки, үзегез борчак шыттырып йөрисездер әле?.. Нигә көләсез? Чынлап әйтәм. Әнә, Ләбиб абыегыз Лерон дәү-ү-ү борчак шыттырып маташа. Әйе!.. Ышанмыйсызмы?.. «Мәгариф» нәшриятында чыккан «Борчак шыттырам» дип аталган китабын алып карагыз (рәссамы - Фәрит Муллахмәт). Бер генә түгел, өч







зур борчактан тора ул. Ягъни бер-бер артлы тезелгән өч кечкенә китапчыктан...

Андагы рәсем, андагы шигырь, андагы маҗара!.. Бер кереп китсәң, кире чыга торган түгел. Әйе, ялганламыйм... Үзем дә Ләбиб абыегызның борчак шыттырганын тыңлап утырам бит әле.

Аның шалтмылтфильмнары, әкиятләре гаҗәп кызык, гаҗәп мавыктыргыч. Шагыйрь абыегызның үзе әйтмешли, сәер ил, сәер дөнья ул «борчаклар»да... Тавыклар да, чебиләр дә һавада оча, каз-үрдәкләр карда коена, мәчеләр болытка кармак салып, балык каптыра, куяннар мультик карап ята, ә балалар кар өстендә кызына!.. Шаккаткыч! Ә Олыймән авылында нинди кызык хәлләр булып ята анда?..

Кырлай тикле Кырлайдан килгән Шүрәле дә Казан буйлап сәяхәт итеп йөри, трамвайда терек-терек килеп, урамнарны гизә, туңдырма ашый. Театрга барып, «Шүрәле» балетын карап утыра... Ялганламыйм, кулда икмәк. Ни хикмәт!.. Сәлим малае Хәлим, Гали батыр, Белемдәр белән Телемдәргә хәтле бар. Әллә каян шат йөзле әкәмәтзатлар да килеп чыкканнар да... Әллә Марстан, әллә Айдан төшкәннәр инде?.. Хәер, Ләбиб абыегыз шыттырган борчакларны үзегез татып карагыз. Ышанмас җирдән ышанырсыз, миңа да рәхмәт әйтерсез... Бер борчак рәхмәт, ике борчак рәхмәт...

Ленар абыегыз ШӘЕХ.



Кадерле дуслар!

Сезнең арада Ләбиб Леронны белмәгән кеше юктыр. Балалар өчен шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, такмаклар, такмазалар, тагын әллә ниләр яза ул. Сезгә бер дигән бүләк әзерләде, «Мәгариф» нәшриятында аның «Кояшны кочкан малай» дигән китабы басылып чыкты. Исеменнән үк күренгәнчә, якты, җылы, нурлы китап. Менә шушы китабы һәм озак еллар балалар матбугатында эшләгәне өчен аның үзенә дә зур бүләк бирелде. Ләбиб Лерон Татарстан Республикасының Муса Җәлил премиясенә лаек булды.

Кадерле дуслар!

Әйдәгез, барыбыз да аны шушы дәрәҗәле, зур бүләк белән котлыйк әле.

Котлыйбыз, Ләбиб Лерон!
Котлыйбыз, Ләбиб абый!

Кадерле малайлар, кызлар!
Өегезгә «Салават күпере» журналы килсә, балачакның күге гел кояшлы булыр, күңелегез төрледән-төрле төсләр яктысыннан балкып торыр.
Журналга язылу бәясе – ярты елга 84 сум.
Индексы – 73953.

Салават күпере

3(204) — 2007

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТАТМЕДИЯ» МАССАКҮЛӘМ КОММУНИКАЦИЯЛӘР АГЕНТЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: АГЕНТСТВО РТ ПО МАССОВОЙ КОММУНИКАЦИИ «ТАТМЕДИЯ», ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта И.ЛЕВИТАН һәм И. ШИШКИН картиналарыннан фрагментлар.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.

Казан, Декабристлар урамы,2 нче йорт.

Производствога бирелде 19.03.2007 ел.
Басарга кул куелды 19.03.2007 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 12510 данә. Заказ Э-358.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, Н.Акмал, З.Вакказова, Г.Сабирова, А. Вакказов.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Бәхтияр ГЫЙЛЬФАН

Яшел моң

И ямьле, гүзәл манзара:
Агачлар иле – Урман!
Хозур урман өсләренә
Сарыла зәңгәр томан.

Агачлар да, үләннәр дә
Үрелеп карый Көнгә...
Урманның яшел моңнары
Агыла тирә-юньгә.

